ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ АБДУЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

# КАРАР

“18” ноябрь 2020 ел Иске Абдул авылы № 13

**“Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлегенең Мерәс авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында”**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы “Иске Абдул авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының нигезендә

## КАРАР БИРӘМ:

1. Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлегенең Мерәс авылында 2020 елның 30 ноябрендә 13.00 сәгатькә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“Иске Абдул авыл җирлегенең Мерәс авылы территориясендә 2021 елда балигъ булган, Иске Абдул авыл җирлегенең Мерәс авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:

-юлларны төзекләндерү

- электроматериаллар сатып алу, урамнарны яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыруны

хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме

“ӘЙЕ” “ЮК”.

3. Татарстан Республикасы, Тукай районы, Мерәс авылы, Сәйдәш урамы, 24 йорт адресы буенча гражданнар җыенын үткәрергә.

4. Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге башкарма комитетын Гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

6. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында “авыл җирлекләре” бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

7. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.

Иске Абдул җирлеге Башлыгы Р.Х.Сафина

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «СТАРОАБДУЛОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ ТУКАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА» РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ОГРН 1061682004735
р 06-5658/09
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СТАРОАБДУЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1639032270